# Фразеологик синонимиядә агач атамалары

**Денмөхәммәтова Э.Н.**

Тикшеренүләр РГНФ (№ 09-04-29404 а /В/ 2009) проектына нигезендә алып барылды

Фразеологик әйтелмәләр дөнья телләренең һәркайсында да булганга күрә, аларда уртак үзенчәлекләр һәм типологик күренешләр, әлбәттә, бар, шуның өстенә тагын һәрбер тел үзендә теге яки бу милләтнең билгеләрен дә саклый. Төрле телләрдәге фразеологик әйтелмәләр уртак юллар белән барлыкка киләләр. Әмма аларны турыдан-туры бер телдән икенчесенә күчкән дип әйтү дөрес түгел, халыкларның фикерләү закончалыклары уртак һәм фразеологизмнар да шул уртаклык нәтиҗәсендә туган булырга тиеш дип санала. Фразеологизмнар составында кулланылган берәмлекләр турыдан-туры мәгънә бөтенлеген бирмәсәләр дә, аларның нинди чолганышта булуы, ничек кулланылулары шулай ук теге яки бу халык аңының үсешен, аңа гына хас уйлауны хасил иткән күрсәткеч булып тора. Шунлыктан фразеологик синоним берәмлекләрдә кулланылган агач атамаларына күзәтү ясау да кызыклы булыр дип саныйбыз. Агач атамалары - төрле телдә сөйләшүчеләр өчен уртак төшенчәләр. Шуңа күрә рус һәм татар телләрендәге агач атамаларының тотрыклы сүзтезмәләр составындагы кулланылышын чагыштырып карау, ике тел вәкилләренең тирә-юньне кабул итүләре арасындагы аермалыкларны һәм охшаш якларын билгеләргә ярдәм итәр дип уйлыйбыз. Эш өчен чыганак материал буларак, Н.Борһанова, Л.Җәләй, Л.Мәхмүтоваларның “Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре”, Г.Х.Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”, Н.Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”, Ф.С.Сафиуллинаның “Русча-татарча фразеологик сүзлеге”, А.И.Молотков җитәкчелегендә 1968 нче елда басылып чыккан “Фразеологический словарь русского языка” хезмәтләре алынды.

Фразеологиядә агач атамаларын куллану еш очрый. Бу кешенең сөйләмдә тирә-юньне, чынбарлыкны ничек чагылдыруы белән аңлатыла. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, рус һәм татар халыклары арасында “агач” атамасы киң урын ала.

Иң элек “агач” атамасына билгеләмә бирү зарур. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә ул түбәндәгечә тәкъдим ителгән:

1) каты кәүсәле, ботаклары ябалдашланып торган күпъеллык үсемлек. Яфраклы агачлар. Ылыслы агачлар. Җимеш агачлары.

2) төзүгә, әйберләр ясауга китә торган агач материал, үзагач;

3) күч. гади с. хур. Аңсыз, аңгыра, надан [5; 15].

“Толковый словарь русского языка” да “агач/дерево” атамасына бирелгән беренче һәм икенче мәгънәләр татар теленеке белән тәңгәл килә, әмма русча сүзлектә аның күчерелмә мәгънәсе күрсәтелмәгән [6; 161.]. Димәк, ике телдә дә уртак мәгънә бар, әмма өстәлмә дә кертелгән. Бу исә ике халыкның бер үк климатта һәм үсемлек тирәлегендә яшәсә дә, татарлар һәм русларның агачларга карата үз мөнәсәбәтләре барлыгын белдерә.

Фразеологик синонимлыкта иң еш кулланылган агач атамалары түбәндәгеләр:

| № п/п | Татар фразеологизмнарында кулланылган агач атамасы | Бу атаманың рус фразеологик вариантта бирелеше | Рус фразеологизмнарында кулланылган агач атамасы | Бу фразеологизмнарның татарча вариантларында бирелеше |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Каен | Береза<br>Тополь<br>Пальма | Береза | Акыл<br>Баш |
| 2. | Тал | Береза<br>Тополь<br>Пальма | Яблоня | Агач |
| 3. | Нарат | Сосна<br>Береза<br>Тополь<br>Пальма | Сосна | *Аннан бер, моннан бер* гыйбарәләре белән |
| 4. | Усак | Осина | Осина | Юк булу |
| 5. | Карама | Вяз<br>Сосна | Ель | Акыл<br>Баш |
| 6 | | | Рябина | Көч җитәрлек түгел<br>Кулдан килми |

Теләсә кайсы халык билгеле бер тирәлектә яши һәм шулай ук аны географик яктан шушы тирәлеккә яраклашкан үсемлек, хайваннар дөньясы чолгап ала. Мәсәлән, без яши торган Татарстанда катнаш һәм куе яфраклы урманнар күп. Шуңа күрә бу урманнарда үсә торган каен, нарат, имән, тал, усак кебек агачлар татар халкының сөйләмендә канатлы әйтелмәләр, тотрыклы сүзтезмәләр, мәкаль-әйтемнәр составында кулланылалар. Шушы ук тирәлектә рус халкы да яши, әмма бу ике халыкның диннәре, ышанулары, көнкүрешләре төрле булганлыктан, алар агач атамаларына башка төсмер бирәләр һәм шул рәвешле тотрыклы гыйбарәләр дә кулланалар. Моннан бер үк агач атамасының ике тел фразеологизмнарында төрлечәкулланылышы барлыкка килә, берсендә ул атама уңай мөнәсәбәтне белдерсә, икенчесендә тискәре төсмер ала.

Мәсәлән, сөйләмдә дә, төрле әдәби әсәрләрдә дә *каен* *а*гачы киң кулланыла. Дөрестән дә, каен төз, матур агач булганлыктан, татар халкы аңа зифа, буй-сынлы кызны сурәтләгәндә мөрәҗәгать иткән. Руслар өчен дә каен – ватанны, гүзәллекне, туган якны тасвирлый торган символ. Каен агачы Россиядә элек-электән күп мәгънәгә ия булган: яучы килгәч, кәләшнең кияүгә чыгарга ризалыгын бирүе дә, җәзалауны белдерүе дә, аның төп мәгънәләре булып тора. Бу ике тел фразеологизмнарында да чагылыш таба: **“Каен чыбыгы ашату – накормить березовой кашей, накормить березовым соком”** (Б.121 - ТРФС). Бу фразеологизмнар кешене җәзалау, чыбык белән суктыру дигәнне аңлата, рус телендәге фразеологизмнарда каша, сок кебек ашамлыклар аша көчерелмә мәгънә белдерелә, ә татар фразеологизмында чыбык сүзе бу вазифаны үти. Шулай ук кешене яткырып, аркасына чыбык белән суктырып җәзалауны Нәкый Исәнбәт үзенең сүзлегендә **“тал чыбыгы ашату”** (Б. 105 - ТТФС , II том) тотрыклы сүзтезмәсен дә тәкъдим итә.

Ике телдә дә кешеләрнең зифа буй-сынын фразеологизмнарда агачка тиңләп күрсәтү сакланып калган, фразеологизмнар да бу очракта тәңгәл килә: **“Яшь каендай – стройная как береза”** (Б.100 - ТРФС). Әмма рус телендә бу мәгънә фразеологизмнарда башка агач атамалары аша да белдерелә. Мәсәлән: **“стройна как тополь, стройна как пальма”** (Б.100 - ТРФС). Татар телендә

исә шул ук мәгънәне Нәкый Исәнбәт тал, нарат атамалары белән дә бирә: **“Тал (чыбыгы) кебек зифа”** (Б. 105 - ТТФС , II том); “**тал чыбыктай”** (Б.223 – ТРФС), **“Нараттай туры”** (Б.100 – ТРФС).

Бу фразеологизмнар синоним буларак карала, әмма аларның мәгънә төсмерләре бердәй түгел. Тал атамасы күпчелек очракта сылу гәүдәле хатын-кызга карата кулланылса, нарат атамасы кергән фразеологизмны ир-атка карата әйтелә дип фаразлый алабыз.

Ике тел вәкилләре өчен дә фразеологизмнарда “усак” атамасының кулланылышы хас. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә аңа түбәндәге аңлатма бирелә: усак – аксыл яшел төстәге шома кайрылы, киртләч яфраклы йомшак агач [5; 19]. Усак агачының, җилдә җилфердәп, “калтырануы” да гомуммәгълүм. Ике халык та, аның шушы билгесен күздә тотып, туңудан, куркудан калтыраган кешегә карата әйтелгән фразеологизмнарда нәкъ менә усакка тиңләүне кулланалар: **“усак яфрагы кебек дерелдәү – дрожать как осиновый лист”** (Б. 263 – ТРФС). Булмый торган җирдән өмет итеп утыруга карата әйтелә торган **“усак алма бирсә”** (Б. 196 – ТТФС) фразеологизмында кулланылган агач атамасы да рус фразеологизмында сакланып калган: **“как на осине груша вырастает” (**Б. 262 – ТРФС). Бу мәгънәне **“как осиновый лист”** (Б. 190 – ФСРЯ) рус фразеологизмында да күрергә мөмкин.

“Нарат” агачы - рус һәм татар теле фразеологизмнарында шулай ук еш очрый торган агач атамасы. Белүебезчә, нарат – мәңге яшел ылыслы агач [2; 54]. Аны авырлыклардан да чыгу юлын тапмау, ап-ачык мәсьәләне дә хәл итә алмау мәгънәсендә кулланганнар, һәм **“өч нарат арасында адашу – заблудиться в трех соснах”** (Б. 201 – ТРФС) фразеологизмы да моны раслый. Татар телендә шушы ук мәгънәне **“ике карама арасында адашып калу”** (Б. 103 – ТРФС) фразеологизмы да белдерә..

“Татарча-русча фразеологик сүзлек”тә агач атамасы кулланылган күпчелек тотрыклы сүзтезмәләрнең ике телдә дә бу компонент ярдәмендә белдерелүе күренә: мәсәлән, **“карама көле сибеп калу”** (Б. 127 –ТРФС) рус теленә **“посыпать золой вяза**” дип тәрҗемә ителә. Мондый тәгъбирләр, гадәттә,

кешене тәмам хур итеп алдаганда, көлкегә калдырганда әйтелүе билгеле. Бар нәрсәне дә эшли алучы, булдыклы кеше турында халык **“таштан юкә суя”** дип әйтә. Рус телендә аны **“из камня лыко дерет”** дигән эквиваленты бар. Шулай ук рус телендә бу әйтелмәнең **“из блохи голенице кроит”, “мастер на все руки”** кебек синоним фразеологизмнары да бар.

Гомумән алганда, агач атамасы булган фразеологизмнар ике телдә дә күп. Кайбер очракларда алар белдергән мәгънә бары төрле берәмлекләр аша гына күрсәтелә: татар телендә бер агач атамасы кулланылса, рус вариантында аны икенче агач атамасы алыштырып килә (карама – сосна, нарат – береза белән алышына).

Агач атамалары кергән әйтелмәләрне татарчадан русчага тәрҗемә иткәндә, алар һәр очракта да калькалаштырылмый, шунлыктан бөтенләй башка синоним фразеологизм барлыкка килә. Мәсәлән: “**кәкре каенга терәтү (терәтеп калдыру) – посадить в галошу; подложит свинью”.** (Б.133 -ТРФС). **“Әлеге дә баягы, шул бер каен таягы – сказка про белого бычка; все то (тот) же (самое)** " (Б. 40 - ТРФС). Соңгы фразеологизмның *каен таягы* урынына *шайтан таягы, болгаткыч таяк* дигән варианты да телдә кулланыла.

**Ә“Каен төбе”, “каенсарга (каен төбенә китү)”** (Б. 121 – ТРФС), **“кәкре каен астына китү”** (Б.440 – ТТФС, I том) фразеологизмнарында агач атамасы үзенең туры мәгънәсен югалткан һәм кабер, зират мәгънәсендә кулланыла. Алар рус телендәге **"последнее пристанище”** (Б.346 – ФСРЯ), **“найти последнее пристанище”** (Б.263 – ФСРЯ) дигән әйтелмә белән тәңгәл килә.

Кешене тәмам хур итеп алдалаганда, көлкегә калдырганда **“карама көленә утырту”, “каеш биреп юкә алу”** (Б.13 – ТТФМӘ), **“агач атка атландыру”** (Б. 30 – ТТФС, I том), **“кәкре каенга терәтү”** (Б.440 – ТТФС, I том), **“юкә агачка атландыру”** (Б. 13 – ТТФМӘ) дигән гыйбарәләр кулланылуы мәгълүм. Русча алар **“обвести вокруг пальца”** (Б.289 – ФСРЯ), **“ставить в неловкое положение”** (Б.451 – ФСРЯ), **“посадить в галошу”** (Б.346 – ФСРЯ) берәмлекләре аша белдереләләр.

Атама кулланылган тотрыклы әйтелмәләрдә агачларның сыйфатлары сакланмаган, алар белән бернинди дә уртаклык табып булмаганнары да бар. Ф.С Сафиуллина үзенең сүзлегендә озын буйлы кешегә карата **“чыршы бизмәне”** фразеологизмын куллана, ә Нәкый Исәнбәт сүзлегендә бу гыйбарә юк, әмма ул шушы мәгънәгә туры килә торган **“торна Вәли”** дигән әйтелмә тәкъдим итә.

Бик якын, бер-берсеннән аерылмас, гел бергә яшәүче ике кешегә карата **“ике инә бер җептә, ике каен бер төптә”** (Б.269 – ТТФС, I том) дип әйтелә. Татар телендә бу әйтелмәнең синонимнары да очрый: **“ике инә бер җептә, ике имән бер төптә”,** (Б. 269 – ТТФС, I том), **“ике тирәк бер төптә, ике төймә бер җептә”.** Рус теленә аларны **“водой не разольешь”, “водой не разлить”, “не разлей вода”** (Б. 382 – ФСРЯ) кебек фразеологизмнар аша тәрҗемә итеп була.

Бер нәрсәгә дә сәләте юк, булдыксыз, булмаган, иркә кешегә карата татар халкы **“кулыннан каткан (шакшы) юкә дә килми”** (Б. 415 –ТТФС, I том) фразеологик гыйбарәсе куллана. Бу гыйбарә рус телендәге **“кисейная барышня”** (Б. 33 - ФСРЯ) дигән әйтелмә белән семантик яктан охшаш булуы күзәтелә.

Рус телендә дә үзара синоним буларак йөри торган фразеологизмнар арасында агач атамаларының кулланылышы шактый. Ә аларны рус теленнән татарчага тәрҗемә иткәндә дә, кайбер компонентлар төшеп калырга, я алар башка сүзләр белән алмаштырылырга мөмкин. Мәсәлән: **“дождешься от вербы яблок”** дигән фразеологик берәмлек беркайчан булмаячак, эшләнми торган эшкә, күренешкә карата әйтелә, татарчага тәрҗемәдә “тал” компоненты кулланылмый, сүзлекләрдә бу берәмлек бары **“абага чәчәк аткач”** диеп бирелә. Әлеге очракта бу компонентның төшеп калуы мәгънәгә зыян китерми, монда нинди мәгънә салынуы үзеннән – үзе ачык аңлашыла. Шулай ук, бу гыйбарәгә синоним булып, рус телендә составына агач атамасы кергән икенче әйтелмәне дә китереп була. Бу **“когда на сосне груши будут”** дигән әйтелмәгә туры килә. Рус фразеологик әйтелмәләрендәге “яблоко”,

“груша” агач җимешләре белән ясалган фразеологизмнар бервакытта да булмас дигәндә кулланылуына ишарә итә.

Алда ук әйтелгәнчә, ныклыкны, көчне рус һәм татар халкы “имән” агачы аша белдергән. Бу барлык фразеологизмнарда да, мәкаль-әйтемнәрдә дә сакланып калган. Мәсәлән, **“крепкий как дуб”** гыйбарәсен базык, нык гәүдәле кешегә карата әйтәләр. Татар теленә бу фразеологизмны, ачач атамасын кулланмыйча гына, “**тегермән ташы”** (Б. 233 – ТРФС)**, “төп кебек”** (Б. 248 – ТРФС), **“төптән юан чыккан”** (Б. 248 – РТФС) әйтелмәләре алыштыра.

Шулай ук хиссез, акылсыз булуны чагылдыра торган рус фразеологизмнары **“дубовая голова”** (Б. 112 – ФСРЯ), **“пень березовый”** (Б. 35 – ФСРЯ) әйтелмәсе аша белдереп була.. Татар телендә бу гыйбарәгә мәгънәви яктан **“акылы (акылга) таман”** (Б.17 – ТРФС), **“башы каты”** (Б. 52 – ТРФС) әйтелмәләре туры килә. Рус телендә исә бу фразеологизмнарга синоним буларак, составында агач атамасы булган **“голова еловая”** (Б.111 – ФСРЯ) әйтелмәсен тәкъдим итеп була.

Надан, хәреф тә танымаган кешегә карата да имән – дуб сүзе кулланыла. Мисалга **“дуб дубом”** (Б. 40 – ТРФС) әйтелмәсен китерергә була. Татар телендә исә бу мәгънәгә **“әлепне таяк, вауны чукмар дип тә белмәү”** гыйбарәсе туры килә. Шулай ук рус телендә **“каждый дуб был когда-то желудем”** дигән гыйбарәдә дә әлеге мәгънә төсмере чагылыш таба.

Мәгълүм булганча, хәзерге вакытта мәгълүмат чараларында күпчелек хәбәрләр, тәрҗемә ителеп, ике телдә дә бирелә. Шунлыктан тәрҗемә итүчеләрдән тотрыклы төзелмәләр белән аеруча сак булу сарала, чөнки турыдан туры тәрҗемә үз-үзен һәрчак акламый, агач атамалары файдаланылган фразеологизмнар да моңа дәлил булып тора.

Шул рәвешле агач атамаларының рус һәм татар фразеологик әйтелмәләрдә бирелешен тикшереп чыккач, аларның ике телдә дә кулланылуы мәгълүм булды һәм тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтте:

1) ике халык та бер үк үсемлек тирәлегендә һәм бер үк климатта яшәсә дә, татар һәм рус халыкларының агачларга карата үз мөнәсәбәтләре булуы

ачыкланды. Мәсәлән, татарлар уңай төсмерне белдергән фразеологизмнарда *тал, нарат, юкә, имән* кебек агачларга, ә руслар *сосна, береза, осина, пальма* кебек агачларга мөрәҗәгать итәләр. Бу фразеологизмнарда тал – зифалык, имән – ныклык һәм бер үк вакытта хиссез, акылсыз булуны да чагылдыруы ачыкланды (как дуб, дуб дубом, имәндә икән чикләвек һ.б);

2) составында агач атамасы булган фразеологизмнар рус һәм татар телендә тирә-юньдәге, чынбарлыкта булган төрле күренешләрне тасвирлау өчен кулланылалар. Күпчелек очракта теге яки бу агач фразеологизмнарда кешенең эш-гамәлләрен чагылдыруда, кешегә бәйле мөнәсәбәттә киләләр. Бу кешенең табигатьнең бер өлеше булган – агачлар белән тыгыз бәйләнештә булуы белән аңлатыла;

3) татар телендәге фразеологик әйтелмәләр рус теленә дә тәрҗемә ителә һәм, киресенчә, рус теленнән күпчелек татар теленә үтеп керүе мәгълүм булды;

4) фразеологик әйтелмәләр һәр очракта да икенче телгә сүзгә сүз күчерелми. Мәсәлән, без карап узган агач атамалары булган әйтелмәләрдә бу компонентның тәрҗемә телендә бөтенләй төшеп калуы белән дә очраштык. Тәрҗемәләр төрлечә бирелә. Бер очракта әлеге компонент бөтенләй төшеп кала, икенче урында ул башка мәгънәдә кулланыла;

5) фразеологик әйтелмәләрдә ярымкалькалаштыру очраклары да мәгълүм булды;

7) составында агач атамалары булган татар фразеологизмнарының күпчелеге уңай мөнәсәбәтне белдерер өчен кулланылса, рус телендә алар тискәре мөнәсәбәтне белдерүләре ачыкланды.

Фразеологик сүзлекләр белән фактик материалны тикшергәч, ике телдә дә еш һәм сирәк кулланыла торган агач атамалары билгеле булды. Ике халык та бер үк климатта һәм үсемлек тирәлегендә яшәсә дә, татарлар һәм русларның агачларга карата мөнәсәбәтләре бераз үзгә булуы ачыкланды. Мәсәлән, татар телендә составына зирек сүзе кергән фразеологизмнар бар, ә рус телендә - ольха кулланылмый; рус телендә тал агачының берничә төре бар

һәм алар, аерым лексик берәмлекләр белән биреләләр (ива, ветла, ракита, бредина), әмма рус телендә бу сүзләр белән ясалган тотрыклы гыйбарәләр булмавы ачыкланды. Татарларда исә тал фразеологиядә яратып кулланыла торган агач. Лиственница – карагай, граб – күгагач, хмельграб – колмакграб, черемуха – шомырт, клен - өрәңге, ясень – корычагач, дардар, черешня – төче чия һ.б. агач атамаларының фразеологизмнарда ике телдә дә сирәк кулланылуы яки бөтенләй кулланылмавын билгеләп үтү зарур. Эвкалипт, шелковица – тут агачы, ефәк агачы, хөрмә һ.б. агачлар татар һәм рус халыклары өчен үзгә агачлар, чөнки алар бары тик җылы климатта гына үсәләр. Әмма шулай да алар, сирәк булса да, фразеология составында очрый.

Шулай итеп кешенең җәмгыятьтәге күпкырлы эшчәнлегенә бәйле рәвештә, телнең барлык структур ярuслары үсеп, үзгәреп тора. Мондый үзгәрешләр фразеологиядә һәм лексикада да чагыла.

Әдәбият

1. Ахатов Г.Х. Фразеологические выражения в татарском языке: Автореф. канд. дисс. / Г.Х.Ахатов. – Казань: Изд. Каз. ун-ва, 1954.

2. Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек / Ф.Г.Ситдиков, Р.К.Зәкиев редакторлыгында. – Казан: Мәгариф, - 1998. – 544б.

3. Копанев П. И. Фразеологизмы и перевод // Проблемы синтаксической семантики: Материалы науч. конф. / Моск. гос. ин-т иностр. яз. – М., 1976. – С. 135-138.

4. Саберова Г.Г. Названия растений в татарском литературном языке / Г.Г. Саберова. – Казань: Изд-во ИЯЛИ, 1995.

5.Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / И.А.Абдуллин, С.Б.Вахитова, Ф.М.Вахитова, Ф.М.Газизов һ.б.: 3 томда. – Т.1. – Казан: Тат.кит.нәшр., - 1977. – 476б.

6.Толковый словарь русского языка / С.И.Ожегов, Н.Ю.Шведова. – М: Азбуковник. – 2001. – 642 с.

7. Юсупов Р.А. Лексико-фразеологические средства русского и татарского языков / Р.А.Юсупов. – Казань: Тат. кн. изд-во, 1980. – 255 с.